СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.13, д. Средняя Корса,
Арский муниципальный район, 422024

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРТА КУРСА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Яшьләр ур, 13 йорт, Урта Курса авылы,
Арча муниципаль районы, 422024

Тел. (84366) 53-4-32, факс (84366) 53-4-32. E-mail: Skor.Ars@tatar.ru

25 октябрь 2019 ел № 100

**Урта Курса авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**Тарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Генераль планын раслау турында**

Урта Курса авыл җирлеге Башлыгының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Генераль планы турында»гы мәгълүматын тыңлаганнан һәм тикшергәннән соң, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты белән килештерелгән 2019 елның 21 октябрендәге «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Генераль планы турында» тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә нигезендә, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 24, 25 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы нигезендә, ачык тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы «Урта Курса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Советы КАРАР бирде:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлегенең Генераль планын яңа редакциядә расларга (карта һәм текстлы нигезләү кушымта итеп бирелә).

2. Урта Курса авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Урта Курса авыл җирлеге Генераль планын раслау турында» 2018 елның 10 октябрендәге 67 номерлы карарын үз көчен югалткан дип таныргa.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), "Арча хәбәрләре" газетасында бастырып чыгарырга һәм "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) игълан итәргә, Урта Курса авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырырга: Урта Курса авылы, Тукай ур., 21, Югары Курса авылы, Мәктәп ур., 16а, Урта Курса авылы, Сәйдәшев ур., 8, Түбән Курса авылы, Мәскәү ур., 30а.

Урта Курса авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Вафина

СОВЕТ
СРЕДНЕКОРСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1609003070